В.М. Усманов

Татар ташъязма ядкярләре

XIII-XVIII гасырлар

Беренче китап

Казан – 2019

ББК 63.4 (2Рос = Тат)
УДК 902
У 74

Китап авторның үз акчасына нәшер ителде

Фәнни мөхәррир:
филология фәннәре кандидаты А.М. Гайнетдинов

Рецензент:
филология фәннәре кандидаты С.Ф. Галимов

Усманов В.М.

Татар ташъязма ядкярләре. XIII-XVIII гасырлар. Беренче китап. – Казан, 2019. – 428 б.: рәс. белән.

ISBN 978-5-9690-0528-0

Бу беренче җыентыкта XIII-XVIII гасырларда иҗат ителгән татар ташъязма ядкярләре турындагы мәгълүмат рәсем-күчермәләр белән бергә туплап бирелгән.

Китап сәнгать белгечләре һәм тарих белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Предлагаемое издание является сводом татарских надгробий XIII – XVIII вв. в виде каталога, составленного из прорисовок с сопровождающими эпитафийными текстами.

Книга адресована искусствоведам и широкому кругу читателей.

ISBN 978-5-9690-0528-0

© Усманов В.М., 2019

Татар ташъязмалары

«Язу калыр кәгазьләрдә заманлар буенча,
язучысы туфракда черегән булыр»
(Эстәрлебаштагы «Мәҗид карый» язмаларыннан)

Кереш сүз

Мәгълүм булганча, Русия дәүләтендә сакланып калган татар (болгар-татар) ташъязмаларын өйрәнүнең ике йөз елга якын бай тарихы бар. Бу юнәлештә бер-ничә дистә белгечләрнең (мәсәлән, ахун Кадыйр-Мөхәммәд Сөнчәләйдән башлап бүгенге тикшеренүче галим Айдар Гайнетдиновка кадәр) бик әһәмиятле хезмәтләре бар. Әлеге көндә, 1271 елдан алып 1740 елга хәтле сузылган дәвердә, меңнән артык татар кабер ташлары исәпкә алынган. (Ни кызганыч, аларның да күп өлеше инде бик аяныч халәттәдер). Алтын Урда чорындагы эпиграфик һәйкәлләрнең саны рәсми рәвештә дүрт йөз чамасы (ә, галим Ф.Хәкимҗанов фикеренчә, фрагментлары белән бергә, алты йөзгә кадәр икән), Казан дәверендәгеләре[1] – өч йөз һәм 1740 елга чаклы язылганнары – йөзгә якын дип исәпләнелә. Болгар вилаятендә барлыкка килгән ташъязма мирасның бер өлеше борынгы төрки шивәсе – «протоболгар» телендә башкарылган булса да, без аларны болгар ташъязмалары дип аерып, басым ясап, атап йөртү ягында түгелбез, чөнки Алтын Урда чорына кадәр Болгар иленә нисбәтле бер ташъязманың да сакланып калуы мәгълүм түгел. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Алтын Урда дип исемләнгән төрки-татар дәүләтендә иҗат ителгән эпиграфик һәйкәлләр – мөселман мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше. Ни өчен? Җавабы бик гади: чөнки, болгар-татар кабер ташлары гарәп хәрефләре белән, фәкать ислам традиция кысаларында башкарылган.

Атаклы археолог А.П.Смирновның «Ташъязмалар Алтын Урданың барлык өлкәләреннән бары тик Болгар җирендә генә таралган»[2] дип язган сүзләре дөреслеккә туры киләме икән? Белүебезчә, Казаннан алып

---

[1]«Шәйбани ханның яхшы соутлары (җырчы-шагыйрь) вә хуп нәкъкашлары (шәп бизәүче рәссамнары) бар. Ул заманда анча соут-нәкъкаш баглар кеше юк иде. Ахыр Шәйбани хан (аларны) Казан ханы Мөхәммәд Әмин ханга җибәрде». (Бабернаме или записки султана Бабера. – Казань: Изд. Н.И.Ильминского, 1857. – с. 230. // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. – Казан: Татар. китап нәшрияты, 1984. – Б.287). Әлбәттә, һичшиксез, алар арасында хаттатлар вә «таш язгучы» осталар да булган.

[2] *Гариф Н.Г.* Болгар-татар ташъязмалары / Булгаро-татарские надгробные камни. – Казан: Иман, 2012. Б.3.

Әстерханга кадәр сузылган Идел елгасының ике як ярларында да бик күп татар шәһәрләре һәм торак пунктлары булган һәм, әлбәттә, шул ташъязма ядкярләрнең иң күп өлеше Сарай Бәркәдә иҗат ителгән. Эпиграфика һәйкәлләрен ясау өчен материал башка төбәкләрдән китерелгәндер, мәсәлән, Кавказ, Кырым тарафларыннан яисә Урта Идел һәм Чулман елгасы ярларыннан.

Ташъязма мирас турында сүз алып барганда, Алтын Урданың Кырым вилаяте һәм Хәрәзем җирләре яисә мәмлүкләргә бәйле Мисыр дәүләтенең булуын да онытмаска кирәк бит әле.

Татар ташъязмаларын өйрәнүнең актуаль бурычлары турында

Сакланып калган ташъязма мирас әсәрләрен кичекмәстән барларга һәм каталоглар рәвешендә бер урынга туплау кирәклеге көн кебек ачык. Беләбез, безгә кадәр дә элекке ташъязмаларны эзләп табу, фотога төшерү, рәсем-эстампажларын ясау, оттиск-күчермәләрен алу, текстларын кәгазьгә беркетү һәм башка шуның кебек бик тә кирәкле эшләр шактый гына башкарылган, дип беләбез. Әмма ләкин монда зур сорау туа: кайда соң алар? Нәтиҗәдә һәм чынбарлыкта бит, яхшы һәм сыйфатлы рәвештә ясалган фоторәсемнәр дә, эстампаж һәм оттиск кебек басма күчермәләр дә архивларда юк, дип әйтергә була, кайберләрен исәпкә алмаганда. (Аларның да күп өлеше, ташъязмалар кебек, сакланып кала алмаган микән ни?) Дөрес, милли музейда боларга бәйле ике-өч зур папка материаллар бар икәнлеген беләбез.

Халкыбызның олуг шәхесләребезнең берсе – Гали Рәхимнең татар эпиграфикасына бәйләнешле искиткеч шәп мәкаләсе бар. Вәләкин ни гаҗәп, аның бу хезмәте үзенең әһәмиятлелеген күп мәртәбәләр киметә. Сорау: ни өчен? Җавап: без аның мәкаләсендә ташъязмалар турында төп мәгълүмат – фоторәсемнәрне күрмибез (берничәсен исәпкә алмаганда). Белүебезчә, аның белән бергә профессиональ фотограф Засыпкин да фәнни экспедициядә катнашкан, ә кайда соң аның ясаган фоторәсемнәре? Бу төп кимчелек башкаларга да кагыла. Дөрес, моңа бәйле хаталар, иң беренче чиратта, кирәк күләмдә акча юклыгы мәсьәләсенә барып тоташадыр. Эпитафияләрне өйрәнү эшендә бит **<u>төп фәнни эш</u>** – сыйфатлы «укымышлы» фоторәсемнәрне алу һәм аларны, мөмкин булганча, бөтен китап битенә (зур рәвештә) тәкъдим итеп матбугатта бастыру. (Монарга өстәп, хәзерге заман мөмкинлекләре чиксез, мәсәлән, электрон варианттагы эш алымнары һ.б.).

Каберташларны өйрәнгәндә фоторәсемнәрне яисә рәсем-күчермәләрне (эстампаж-оттискларны) санга сукмау, аларга төп игътибарны күрсәтмәү

фәнни эш түгел дигәнне аңлата. Татар ташъязмаларын өйрәнү өлкәсендә бик күркәм үрнәкләр бар бит. Искә төшерәбез: мәсәлән, В.Вельяминов-Зернов яисә С.Е.Малов хезмәтләрендә тәкъдим ителгән үрнәк эш алымнарын, яңа ысуллар белән бергә, яңа заман мөмкинлекләрен кулланып ник дәвам итмәскә? Ә бит бу рәвештә фәнни эшне алып бару, беренчедән, реконструкция ясау өчен уңайлы; икенчедән, зур чыгымнар таләп итми; өченчедән, (сыйфатсыз) фоторәсемгә караганда, «прорисовка»лы текстлар аңлаешлырак күренә; дүртенчедән, элекке типографик ысул белән гади кәгазьгә басылып нәшер ителгән аклы-каралы күчермәләр, затлы һәм купшы китаплар белән чагыштырганда, яхшырак саклана ала (шуңа күрә дә инде ул элек-электән «ташбасма» дип аталган, ягъни ташка баскан кебек нык була). «Прорисовка»лар ясау гарәп язуына палеографик яктан да якын килеп, нindидер кимәлдә, җентекле анализ ясауны күрсәтә. Аңлашыла ки, дөрес укылган ташъязманың гына реконструкциясен ясап була. Кыскасы, югарыда әйтеп үтелгән урыс галимнәренең китапларында һәм мәкаләләрендә китерелгән эстампаж мәгълүматлары һәм аңлатмалары безне тулысынча канәгатьләндерә һәм өлге була ала. Чөнки анда барлык кирәкле төп чыганаклар һәм белешмәләр күрсәтелгән: ташъязма истәлекнең төс кыяфәте (бизәк-язулары, алды-арты, кырлары), үлчәмнәре, укылышлары һ.б.

Монда Казан галимнәреннән Н.Ф.Калинин хезмәтләрен дә аерым билгеләп үтәргә кирәк. Бу олуг шәхес, тарихчы, сәнгатьче, телче һәм башка белгечләр күзлегеннән чыгып, татар ташъязмаларын өйрәнүгә, зур эш башкаруга ирешкән. Биредә шулай ук Һ.Йосыпов, Ф.Вәлиев, Ф.Хәкимҗанов, М.Әхмәтҗанов, Җ.Мөхәммәтшин, Р.Мәрданов, И.Һадиев, Н.Гариф һәм югарыда искә алынган А.Гайнетдинов кебек зур галимнәребезнең дә хезмәтләрен уңай яктан гына искә алып китәбез.

Татар эпиграфикасын тирәнтен өйрәнгәндә[3], әлбәттә, түбәндәге тәртипләрнең кулланылуы мотлак:

1) хронологик принцип;
2) географик принцип;
3) типологик принцип;
4) палеографик принцип[4];
5) лингвистик принцип.

---

[3] Бу принцип-тәртипләр турында кара: *Мухаметшин Д.Г.* Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей». – Выпуск 6. – Казань: Институт истории АН РТ, 2008. 132 с. илл.

[4] Игътибар итсәгез, ни сәбәпледер, сәнгать белгече Ф.Вәлиевнең хезмәтләрендә бу принципка игътибар бирелмәгән.

Шулай итеп, татар ташъязмаларын өйрәнү эшендә, беренчедән, (сыйфатлы, ягъни яхшы «укымышлы» фоторәсемнәрдән башка) төгәл үлчәмнәрне һәм координаталарны алу кирәк. Икенчедән, ташъязмадагы төп мәгълүмат ул эпитафиядән эпитафиягә кабатланып күчә барган «шаблон» җөмләләр түгел (аңлыйбыз, анысы да бик кирәк), ә безгә әһәмиятлерәк булган, турыдан-туры татар халкының тарихына, теленә, аның күренекле шәхесләренә кагылышлы уникаль мәгълүматлар (мәсәлән, мәрхүм-мәрхүмәләрнең исемнәре, кем улы (яисә кем кызы) икәнлекләре, биләгән вазыйфалары, кайдан һәм кайчан яисә ничә яшьтә вафат, һәлак булулары, ташны кем язган[5] йә яздырткан һәм башка шуның кебек белешмәләр). Монда, игътибарны читкә тайпылдыртмыйча һәм вакытны бик кирәкле булмаган «вак мәсьәләләргә» сарыф итмичә, дөрес юнәлештә эш алып бару кирәк. Мәсәлән, Казан ханлыгы чорындагы ташъязмалардагы төп мәгълүматларны нәрсә тәшкил итә соң?

Җавап:

- Сыйфатлы фоторәсем.
- Кабер ташларының аскы өлешендәге, ягъни астан дүртенче, өченче һәм икенче юлларындагы мәгълүмат безнең өчен бик мөһим. Ни өчен? Чөнки бу урында (кабатлап әйтеп үтәбез) җирләнгән тарихи шәхеснең исем-шәрифләре, кем һәм кайдан икәнлеге, кайчан вафат яисә ни сәбәпле һәлак булуы күрсәтелгән. Бу – безнең өчен иң кирәкле «бердәнбер» мәгълүмат, ягъни эпитафия текстының «йөзек кашы». Сакланып калган бу өлешен укый алмау яисә төгәл укымау безнең иң зур кимчелегебез буладыр. Дөрес укылган җөмләләр белән бергә, ялгыш укылган сүзләрнең дә транскрипциясен, транслитерациясен латинга бәйле символлар белән укучыларга тәкъдим итүнең яисә чит телләргә аударылган тәрҗемәләрен башкарып, дөньякүләм фән дәрәҗәсенә күтәреләбез, дип, шул хаталы «фәнни ачышларыбызны» җир шары киңлекләренә таратуның ни мәгънәсе бар? Әлеге көндә дә бихисап төгәлсезлекләр бер китаптан икенче китапка күчә баруын дәвам итә (мәсәлән: سيد اق «**Сәйид Ак**» дип уку урынына «Шайдулла»; نوقراتدا شهيد كيجدي «**Нукратда шәһид_кижде**» – « Казанда шәһид кичде», « Суаш кырында шәһид кичде» яисә «Каранда шәһид кижде»; اليكج اوغلي كوجك حافظ «**Әликәч углы Көчек хафиз**» – «Галикәч углы Хаккау Хафиз»; جيرميش اوغلي ياماش «**Чирмеш угылы Ямаш**» –

[5] Мәсәлән, XIX-XX гасырлар чатында, Казан шәһәрендә гомер кичергән “таш язгучы” осталарның исемнәре мәгълүм: Габделбарый әл-Мөэмини әл-Баруди, Фәтхелкадыйр Кәлметов, Кавам карый Зөлфокаров, мөәззин Шәрифҗан, Мостафа әл-Чутаи, Нурый Буртасый һ.б.

«Абыз Риким Чиремеш угылы»; محمد اوعلي تيلاش «**Мөхәммәд угылы Тиләш**» – « Бикмөхәммәд угылы Тиләш»; بيك اوعلى مرزا مناص ممتاك « **Мәмәтәк бик угылы морзa Мәнас**» – « Ил-аул сәид Атабик Мәннан морза угылы» яисә «әүвәл аенда Үтәк бик Мәннан морза угылы»; يوز يكرمي اوج حاجي رمضان اغلي سيداحمد «**йөз йегерме өч хаҗи Рамазан углы Сәид Әхмәд**» – «бу ләүхне бина кылды хаҗи Рамазан») һ.б. шуның кебек вариантлар[6].

Гомумән, без – татар эпиграфикасын өйрәнүчеләр – беренче нәүбәттә, фәнни эшебезне бергәләшеп-бердәмләшеп, камиллеккә омтылып, башкарырга тиешбез[7].

---

[6] Ташның арткы ягында: «бу ләүхәне...(фәлән исемле кеше – У.В.) бина кылды» дигән сүзләрнең булуы да безнең өчен бик мөһим.

[7] Шунысын да искәртеп үтәргә кирәктер, төзәтмәләр яисә өстәмәләр кертү өчен, кайбер истәлекләргә күп мәртәбәләр, кабаттан, кире әйләнеп кайтулар еш булыр әле, дип көтелә. انشاالله

Беренче өлеш

XIII-XIV гасырлар

№ 1

1 нче өлеш : 1 нче бүлек : № 1 таш.

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы.[8] 1315–1330 еллар арасы. Коры Көрнәле, Алексей районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
1) *Әл-хөкме лилләһи*	الحكم لله
2) *Әл-Гали әл-Кәбир*	العلى الكبير
3) Көллү нәфсин заикат-	كلنفسذايقة
4) ел-мәүт сөммә иләйнә түр-	الموت ثم الينا تر
5) җәгунә	جعون
6) .... зиярәте	......زيارت ى ......
7)	....
8) .... *Бәлтүк*	بلتك..........

Үлчәмнәре : 19×38×69 см.
Координаталары: N 55° 08. 809 E 50° 01. 759 .

Текст гарәп һәм протоболгар телләрендә язылган.

[8] Бу ядкяр турында кара: ЦПиМН ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова АН РТ, ф.53 (фонд С.Вахиди), 1 опись, 58 ед.хр.; Духовное наследие: поиски и открытия / Под ред. И.Г.Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Вып.4. – 280 с.; *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. – М.: Наука, 1978. – 164-165 стр.; Коры Көрнәле авылы тарихы. Составители: Гумеров И.Г., Усманов В.М. – Казан, 2018. – 23 б.

№2

1 : 1 : № 2.

Гомәр Хөсәен улына куелган кабер ташы[9]. 1325 ел.

Коры Көрнәле, Алексей районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
1) *Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир* 2) Хаҗи Хөсәен улы хум 3) Гомәр бәләвике. *Рәхмәтуллаһи* 4) *галәйһи рәхмәтуллаһи васигатән.* Ваф- 5) ат балтави тарих җиати 6) җүр җирем алтысы җал 7) сафәр айхы җиареме алтысы 8) күән әте	الحكم للّٰه العلى الكبير حاجى حسين آول حوُم عُمَر بَلوُي كُ رحمَة اللّٰه عَلَيه رَحمَةً وَاسعَه وَفا تُ بَلطوُي تَارِيخُ جِيَاتِ جوُر جِيرم آلطِسِى جَال صَفَر آيح جِيرم آلطِسِى كُوَان آتِ

Үлчәмнәре : 19×49×100 см.
Координаталары: N 55° 08. 815' E 50° 01. 746'.

Текст гарәп һәм протоболгар телләрендә язылган.

Искәрмә: «Син» дә өч, «Та» хәрефе астында бер нокта куелган.

---

[9] Бу ядкяр турында кара: ЦПиМН ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова АН РТ, ф.53 (фонд С.Вахиди), 1 опись, 58 ед.хр.; Духовное наследие: поиски и открытия / под ред. И.Г.Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Вып.4. – 280 с.; *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. – М.: Наука, 1978. – С.124-125; Коры Көрнәле авылы тарихы. Төзүчеләр Гумеров И.Г., Усманов В.М. – Казан, 2018. – Б.24.

№ 3

1 : 1 : № 3.

Гайсә Госман улына куелган кабер ташы[10]. 1324 ел. Коры Көрнәле, Алексей районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
1) *Әл-хөкме лилләhи әл-Гали әл-Кәбир* 2) Госман улы Гайсә зыярә- 3) те. *Рәхмәтуллаhи галәйhи рәхмәтән* 4) *васигатән.* Тарих 5) җиати җүр җиарем тәва- 6) тем җал зөлхиҗҗә 7) айхы ун сигез күән 8) әте	الحكم لله العلى الكبير عثمَاَن اولِ عيسى زيار ت ى رَحمَةَ الله عليه رحمة وَاسعة تارِيخ جيات جور جيارمتوا تمجالذي الحجه ايخ ون سكر كوان ات

Текст гарәп һәм протоболгар телләрендә язылган.

Искәрмә: «Син» хәрефләре астында өч нокта куелган.

Үлчәмнәре : 20×53×122 см.

Координаталары: : N 55° 08. 817' E 50° 01. 742'.

---

[10] Бу ядкяр турында кара: ЦПиМН ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова АН РТ, ф. 53 С.Вахиди , 1 опись, 58 ед.хр.; Духовное наследие: поиски и открытия / Под ред. И.Г.Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Вып.4. – 280 с.; *Хакимзянов Ф.С.* Язык эпитафий волжских булгар. М.: Наука, 1978. – 122-123 стр.; Коры Көрнәле авылы тарихы. Төзүчеләр: Гумеров И.Г., Усманов В.М. – Казан, 2018. – 25 б.

№4

1 : 1 : № 4.

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы[11]. XIV гасыр. Коры Көрнәле, Алексей районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
1) *Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир* 2) .... 3) .... 4) Тарих 5) [җиати] 6) җүр	الحكم لله العلى الكبير .... [تارِيخ] جِيَاتِ .... جوُر ....

Үлчәмнәре : 17×72×126 см.

Координаталары: N 55° 08. 838' E 50° 01. 742'.

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

---

11 Бу ядкяр турында кара: ЦПиМН ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова АН РТ, ф. 53 (фонд С.Вахиди), 1 опись, 58 ед.хр.; Духовное наследие: поиски и открытия / Под ред. И.Г.Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Вып. 4. – С.280; Коры Көрнәле авылы тарихы. Төзүчеләр: Гумеров И.Г., Усманов В.М. – Казан, 2018. – Б.27; *Мухаметшин Д.Г.* Татарские эпиграфичечские памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей». – Выпуск 6. – Казань: Институт истории АН РТ, 2008. – 132 с. илл.; *Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. – Казань, Татарское кн. изд-во, 1984. – 188 с. с илл.

№5

1 : 1 : № 5.

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы[12]. 1320–1340 еллар. Коры Көрнәле, Алексей районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
1) *Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир* 2)	هوَ الحَى الذى لا يموت ....

Үлчәмнәре : 20×42×50 см.

Координаталары: N 55° 08. 796'   E 50° 01. 876'.

Текст гарәп телендә башлана.

[12] Бу ядкяр турында кара: ЦПиМН ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова АН РТ, ф. 53 (фонд С.Вахиди), 1 опись, 58 ед.хр.; Духовное наследие: поиски и открытия / Под ред. И.Г.Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Вып.4. – 280 с.; Коры Көрнәле авылы тарихы. Төзүчеләр: Гумеров И.Г., Усманов В.М. – Казан, 2018. – Б.29.

Ульян өлкәсендәге татар эпитафик һәйкәлләр.

№ 6

1 : 2 : № 1.

Төйҗә [Коддус] улына куелган кабер ташы.

XIV гасырның беренче яртысы. Татар Калмаюр авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
1) *Һу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт* *2) вә көлли нәфсин заикател-мәүт* 3) [Куддус углы] 4) Төйҗә зияраты торур 5*) рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән* *6) васигатән* тарих йете йөз 7) иллик тукуз да шәүвәл 8) айхы 9)	هوالیالذیلایموت وکل نفس ذایقة الموت .... تویجا زیارتی ترور رحمة الله علیه رحمة واسعه تاریخ یتی یوز ایلیک توقوزدا شوال ایحی ....

Ташның уң ягында бик начар хальдә сакланып калган кайбер хәрефләр:

1 : 2 : № 1 : Б - рәсем
عوا لا ر فيها وان
لا ر ف

Ташның сул ягында бик начар хальдә сакланып калган кайбер хәрефләр:

1:26:№ 1: Г - рәсем
للعبا سو الـ وس مزن لـ
و ان هفو هفو الرب غفار

Үлчәмнәре: 21×63×136 см.

Координаталары: N 54°12. 891’
E 048° 58. 394’

Текст гарәп вә төрки (протоболгар һәм татар) телләрендә язылган.

№ 7

1 : 2 : № 2.

Инәбәк Байкара улына куелган кабер ташы.

XIV гасырның беренче яртысы. Татар Калмаюр авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
1) Байкара углы 2) Инабәк зияраты 3) *рәхмәтуллаhи галәйhи* *4) рәхмәтән васигатән*	بايقرااوعلى اينەبك زيارتي رحمة الله عليه رحمةواسعة

Үлчәмнәре: 17×41,5×75 см.

Координаталары: N 54°12. 923’ E 048° 58. 391’

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

№ 8

1 : 2 : № 3.

Котлыг-бәк углы Котлыг-Тимер улына куелган кабер ташы. 1356 ел. Татар Калмаюр авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
• ...... • *Әл-хөкме лиллаhи* • Котлыг бәк • углы Котлыг • Тимер ... • тарих йете йөз • иллек сикездә ... • .... ирде	لله الحم قو ثلوغ بك اوعلى قوثلوغ ثمور ثاريخ پثىپوز ابلبك سبكزدا دا عرسبر ا بردى

Үлчәмнәре: 21×51×(69+73) 142 см.

Координаталары: N 54°12. 923′ E 048° 58.394’

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

№ 9

1 : 2 : № 4.

Әр-хуҗа Йөз-Көч улына куелган кабер ташы[13]. XIV гасырның беренче яртысы. Татар Калмаюр авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
1) *Һу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт* *2) вә көлли Хәййе сәйәмүт* Йөз 3) [Куддус углы] 4) Төйҗә зияраты [торур] 5) *рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән*	هوالىالذىلايموت و كل حى سيموت يوز كوج اول ارخواجه زيارةى رحمة الله عليه رحمة واسعه

Үлчәмнәре: 20×58×100 см.

Координаталары: N 54°12. 931’ E 048° 58. 439’

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

Искәрмә: س « Син » хәрефләре астында өч нокта куелган.

[13] Бу ядкяр турында кара: Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. – М.: Наука, 1978. – С.168.

№ 10

1 : 2 : № 5.

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган, 1353 ел.

Татар Калмаюр авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
• ………………………………………….. • Тарих йете йөз иллек • түртдә мөхәррәм ае • ………………………………………..	……………………. …………. تاریخ یتی یوز الیك تورت دا محرم ایی

Үлчәмнәре: 25×60×108 см.

Координаталары: N 54°12. 881’ E 048° 58.388’

Текстның сакланып калган өлеше татар телендә язылган.

№ 11

1 : 2 : № 6.

Шәба-Билек улына куелган кабер ташы[14]. XIV гасыр. Татар Калмаюр авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
1) *Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир* 2) Шәба Билек улы 3) …………………………….. 4) айхы .... 5)	الحكم لله العلى الكبير شبا بيلك اول …… ايح…… …………

Вариант: Шабайбәк (?)

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

[14] Улйан шәһәрендәге төбәкне өйрәнү музеенда саклана.

Енганаево (Үрән) авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

№ 12

1 : 2 : № 7.

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы. (Фрагмент, ташның аскы өлеше). Енганаево (Үрән) авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Язулары сакланмаган.

Үлчәмнәре: 22×67×66 см.

Координаталары: N 54°25. 793′ E 048° 53. 568′

№ 13

1 : 2 : № 8.

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы. (Фрагмент, ташъязманың аскы өлеше). Енганаево (Үрән) авылы, Чардаклы районы, Ульян өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Текст
..................جال ات
Укылышы
1)……………………… җал 2) әте.

Үлчәмнәре: 19х44-50х71 см.
Координаталары: N 54°25.820ʹ E 048° 53. 570ʹ

Текстның сакланып калган өлеше протоболгар телендә язылган.

Алтын Урда ядкярләре

№ 14

1 : 3 : № 1 : А

Мигъмари бизәк

№15

1 : 3 : № 2 : А

Габдулла кызы Дәүләткә куелган кабер ташы.

Кырым. XIV гасыр. Сакланган урыны - дәүләт Эрмитажы.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
• *Аллаһу* • һаза төрбәтү Дәүләт • бинте әл-хаж Габдулла	الله هذاتربةدولت بنتالحاخعبدالله

Шәһре Болгар һәм
Болгар виляяте ядкярләре

(Уйма язулылары)

№ 16

1 : 4 : № 1 : А

Сүс Алтын би кызына куелган кабер ташы[15].

XIII – XIV гасырлар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
1) *Көллү нәфсин заикател-мәүт* 2) *сөммә иләйна түрҗәгунә* Алтын би һир * Сүс 3) алыб бетек 4) *рәхмәтуллаһи* 5) *галәйһи рәхмәтән васигатән*	كل نفس ذايقة الموت ثم الينا ترجعون الطن بو هير سوس الب بطيك رحمة الله عليه رحمة واسعة

Үлчәмнәре: 12 ˣ 45 ˣ 77 см.

*Сүзлектән кара.

[15] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.56.

№ 17

1 : 4 : № 2 : А

Билгесез. 1291 нче елда язылган таш (фрагмент)[16].

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә башкарылган.

Алгы ягында (уйма язулы):

Тәрҗемәсе	Текст
1) ахирәткә күчте 2) алты йөз туксанынчы 3) елда шагбан аеның бишенче 4) көнендә Аллаһның рәхмәте 5)	احرةبطوى هجرة رانالطجوزطحور اوانمجالشعبانايحبلنج كوانااتاللهرحمة عطنطمحو

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

[16] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.3.

№ 18

1 : 4: № 3 : А

Гали Мәмли углына куелган кабер ташы[17]. Кайчан язылганы билгеле түгел.

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә башкарылган.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
• *Әл-хөкме Лилләһи* • Мәмли углы • Гали билгесе	الحكملله مملاول علىبلوىك

[17] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.42.

№ 19

1 : 4 : № 4

Сөбәйтә исемле хатын-кызга куелган кабер ташы[18].

XIII - XIV гасырлар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
1) *hу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт* 2) .... кызы 3) Сөбәйтә билгесе 4) *Рәхмәтуллаhи галәйhа* 5) *рәхмәтән васигатән*	هوالحىالذىلايموت هير سبيتبلوىك رحمةاللهعليها رحمهواسعه

[18] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.43.

№ 20

1 : 4: № 5

Йәлбә кызы Асияга куелган кабер ташы[19]. Кайчан язылганы билгеле түгел.

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә күфи язуында башкарылган.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
• *Әл-хөкме Лилләһи* • Йәлбә һире • Асия зиярәте • *рәхмәтуллаһи галәйһа* • *рәхмәтән васигатән*	الحكم لله يلبه هير اسيه زيارةى رحمةاللهعليها رحمة واسعة

Үлчәмнәре: 13 х 46 х 84 см.

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

[19] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.40.

№ 21

1 : 4: № 6

Татар Бәлтүк кызына куелган кабер ташы[20]. Кайчан язылганы билгеле түгел. Олы Әтрәч авылы, Апас районы.

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә күфи язуында башкарылган.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
• *әл-хөкме Лилләһи* • *әл-Гали әл-Кәбир* • Татар Бәлтүк • һире Хәҗимә бәлүи- • ке *рәхмәтуллаһи* • *галәйһа рәхмәтән васигатән*	الحكم لله يلبه هيرالعلىالكبير ططر بلتك هيرحجمبلوى كرحمةالله عليهرحمة واسعة

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

Искәрмә: “ط”, “ر”, “ع” хәрефләре астында берешәр нокта бар.

---

[20] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.41.

№ 22

1 : 4: № 7

Әтрәч улына куелган кабер ташы[21]. Кайчан язылганы билгеле түгел. Олы Әтрәч авылы, Апас районы.

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә куфи язуында башкарылган.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
• *Һу әл-Хәййе әл-ләзи* • *ля йәмүт* Госман • улы Әтрәч улы • [Бөдәс] бәләви[ке] • *рәхмәтуллаһи галәйһа*	هوالحىالذى لايموتعثمان اول اترج اول بلوى رحمةالله

Үлчәмнәре:43 х 85 см.

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

Искәрмә: س " Син " дә өч, د " Дәл ", ر " Ра ", ع " ʿАйн " хәрефләре астында берешәр нокта бар.

[21] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.20.

№ 23

1 : 4: № 8

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы[22]. 1288 ел. Шәһре Болгар.

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә күфи язуында башкарылган.

Алгы ягында (уйма язулы):

Тәрҗемәсе	Текст
• һиҗрәтдән алты • йөз сиксән җиденче • җылының көне иде	هجرةران الط جورسكروانجياتش جال كوان ات

Үлчәмнәре:17 х 42 х 50 см.

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

[22] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл. 6.

Болгар виляяте ядкярләре

(Уйма язулылары)

№ 24

1 : 5 : № 1

Исхак Ибраһим угылына куелган кабер ташы[23].

1399 ел. Олы Нырсы авылы, Теләче районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
• *бисмиллаһир-Рахманир-Рахим* • *көллү нәфсин заикател-мәүт* • *көллү хәййе ля йәмүт* тарих сикез • [йөз] икедә мөбарәк мөхәррәм а[еның] • ун алтынчы көн ирде кем • Ибраһим углы Исхак • утыз алты яшендә ирде кем • фани дүнйадин бакый .... • *[рәхмәт]уллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән*	بسم الله الرحمن الرحيم كل نفس ذايقة الموت كل حى لا يموت تاريخ سكيز يوز ايكى دا مبارك محرم اى نك اون التنجى كون ايردى كيم ابراهيم اوعلى اسحاق اوتوز التى ياشندا ايردى كيم فانى دنيادين باقى قيلدى رحمة الله عليه رحمة واسعة رحمه واسعه

[23] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.45.

№ 25

1 : 5 : № 2

Йосыф Шәйех угылына куелган кабер ташы[24].

1443 ел. Олы Нырсы авылы, Теләче районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
• *бисмиллаһир-Рахманир-Рахим* • *көллү нәфсин заикател-мәүт* • *сөммә иләйна тәрҗәгун калә* • *ән-нәби галәйһа әс-сәлям әл-кабр* • *раузат мин риязый әл-җәннәт* • .... тарих • сикез йөз кырык йетедә сафәр аенының • .... ирде Йосыф ибне Шәйех • дарелфәнадин дарелбәкага рихләт кылды *гафәрә Аллаһу*	بسم الله الرحمن الرحيم كل نفس ذايقة الموت ثم الينا ترجعون قال النبى عليه السلام القبر روضة من رياض الجنة او حفرة من حفرة النيران تاريخ سكيز يقوز قرق يتى دا صفرا ى ننك عرسندا ايردى يوسف ابن شيخ دار فنادين دار بقا عا رحلت قيلدى عفر الله له ولو الديه

Искәрмә: Кайбер гарәп хәрефләре өстендә я астында өстәмә нокталар бар.

Текст гарәп һәм татар телендә язылган.

[24] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.51; *Нотфуллина Р.* Нырсы изгеләре. Безнең мирас. – № 11 (287), ноябрь, 2017. – Б.14-20.

№ 26

1 : 5 : № 3

Сөләйман Исүх угылына куелган кабер ташы[25].

1357 ел. Олы Нырсы авылы, Теләче районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
• *Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир* • Исүх улы Сөләйма- • н улы Шәйех з- • ияраты рәхмәтуллаһи • галәйһи рәхмәтән васигатән • тарих җиати җүр • илү сикез җал ..... • рамазан аихы әт	الحكم لله العلىالكبير اسح اول سليما ن اول شيخ ز يارةى رحمةاللهعليه رحمة واسعة تاريخجياتجور الوسكرجال رمضانايحات

Искәрмә: Кайбер гарәп хәрефләре өстендә я астында өстәмә нокталар бар.

Үлчәмнәре: 21 × 63 × 150 см.

Текст гарәп һәм протоболгар телендә язылган.

[25] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.29.

№ 27

1 : 5 : № 4

Хармас Госман кызына куелган кабер ташы[26]. XIV гасыр. Олы Әтрәч авылы, Апас районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
• *Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир* • Госман кызы Хармас 1) бәләүике рәхмәтуллаһи 2) галәйһи рәхмәтән васигатән 3) вафат балтави 4) тарих җиати җүр 5)	الحكم لله العلى الكبير عثمان هير حرماس بلوىك رحمهالله عليها رحمة واسعة وفاتبلطوى تاريخجياتجور

Искәрмә: Кайбер гарәп хәрефләре өстендә я астында өстәмә нокталар бар.

Үлчәмнәре: 46 × 82 см.

[26] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.18.

№ 28

1 : 5 : № 5

Салихка куелган кабер ташы[27]. XIV гасыр.
Иске Ашыт авылы, Арча районы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	Текст
• *Һу әл-Хәййе әл-ләдзи* • *ля йәмүт вә көлли Хәййе сәйәмүт* • Болгар .... улы Салих • зияраты рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән • васигатән фани дүнйадан • ... бакый ахирәт .... • Тарих җиати җүр • ... бәлех күән әт	هوالحیالذی لایموتوکلحیسیموت بلعارتطیاولصالح زیارةی رحمةاللهعلیه رحمة واسعة فانی دنیادان باقیاحرة تاریخ جیات جور جال بلح کوان ات

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә башкарылган.

Үлчәмнәре: 21 x 60 x 80 см.

№ 29

[27] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.31.

1 : 5 : № 6

Әлхәмәд Әхәҗ улына куелган кабер ташы[28] (фрагмент). XIII - XIV гасырлар. Батрак авылы янәшәсе, Самара өлкәсе.

Алгы ягында (уйма язулы):

Укылышы	**Текст**
• *[Көлли нәфсин-заикател-] мәүт сөммә иләйна тәрҗәгуән* • Әхәҗ улы Әлхәмәд • беләүике Аллаһ р- • әхмәти ... •	موتثم اليناترجعوان احجاولالحمد بلوىكاللهر حمةاطنط

Текст протоболгар һәм гарәп телләрендә башкарылган.

Үлчәмнәре: 76 х 92 см.

[28] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл. 50.

Болгар вилаяте ядкярләре

(Калку язулылары)

№ 30

1 : 6 : № 1

Исмәгыйль йуари кызына куелган кабер ташы[29]. XIV гасыр. Таутегермән авылы, Теләче районы.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир* • Исмәгыйль йувари .... • .... һире .... • Кәмал .... • .... рәхмәтән	الحكم لله العلى الكبير اساماعيل يوارى هيرى كمال‌مار رحمه

Үлчәмнәре: 25 х 73 х 176 см.

[29] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.37.

№ 31

1 : 6 : № 2

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы (фрагмент). XIII - XIV гасырлар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
• *hу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт .....* •	هوالحىالذىلايموتوكلحىسيموت ....

Текстның сакланган өлеше гарәп телендә язылган.

№ 32

1 : 6 : № 3

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы[30] (фрагмент). XIII - XIV гасырлар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
• *һу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт .....* •	هوالحىالذىلايموتوكلحىسيموت ....

Текстның сакланган өлеше гарәп телендә язылган.

Ядкяр Казан шәһәренең Дәүләт музеенда саклана.

[30] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. –М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.2.

№ 33

1 : 6 : № 4

Хәсән-бәк Мир-Мәхмүд угылына куелган кабер ташы[31]*. XIII гасыр азагы. Ханнар зираты “Архиерей бакчасы”, Казан шәһәре.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *һу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт* ..... • .... • Хәсән бәк бине Мир Мәхмүд	هوالحى الذى لايموت وكل حى سيموت .... حسن بك بن محمود

Үлчәмнәре: 38-40 х 92-96 х 350 см.

Текстның сакланган өлеше гарәп һәм татар телләрендә язылган.

Ядкяр Казан шәһәренең Дәүләт музеенда саклана.

№ 34

[31] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.2.
*Ары таба, бу ташъязманың күчермә-реконструкциясен яңа осуллар кулланып ясау таләп ителәчәк.

1 : 6 : № 5

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы. XIII - XIV гасырлар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *hу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт .....* •	هوالحىالذىلايموتوكلحىسيموت ....

№ 35

1 : 6 : № 6

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган кабер ташы[32] (фрагмент). 1328 ел.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *hу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт .....* •	هوالحىالذىلايموتوكلحىسيموت ....

Ядкяр Казан шәһәренең Дәүләт музеенда саклана.

Үлчәмнәре: 58 x 107 см.

[32] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. –М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.22.

№ 36

1 : 6 : № 7

Алтынчы Шаһидулла угылына куелган кабер ташы[33]. 1317 ел. Шәһре Болгар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *һу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт* • йегетләр күрке күңелләр үзәге • галимләрне агырлаган йәтим тол • үксүзләрне асраган Муса углы • алтынчы Шәһидулла зияраты ...... • .... кылсын ... рәбигыл-әүвәлнең уртасы • тарихка 717	هوالحیالذیلایموت یکتلار کورکی کونکللار اوزکی عالملارنی اعرلاعان یتم تول التونجي شهیداللهزیارتی قیلسون ربیعالاولنك اورتاسیتاریخقا٧١٧

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

[33] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов (1),* Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.15.

Шәһре Болгар ядкярләре

(Күфи хәрефендәге калку язулылары)

№ 37

1 : 7 : № 1 : А

Бәлтүләк угылына куелган кабер ташы[34]. Шәһре Болгар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *һу әл-Хәййе әл-ләдзи ля йәмүт* • *вә көлли Хәййе [сәйәмүт]* • Бәлтүләк у [лы] ... зия- • раты р[әхмәтуллаһи галәйһи] • рәхмәтән ва[сигатән дүнйа-] • дан сәфәр ... [... тар -] • их җиати [җүр] • биалим	هوالحى الذى لايموت وكل حى سيموت بلتلك اول زيا رتى رحمة الله عليه دان سفر تار يخ جيات جور بيالم

Үлчәмнәре: 18 x 43 x105 см.

Текст гарәп һәм протоболгар телләрендә язылган.

---

[34] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.39.

Икенче өлеш

XVI гасыр *(1445 – 1552 еллар)*

.

№ 38

Икенче өлеш : 1 нче бүлек : № 1таш.

Кемгә куелганы билгесез кабер ташы. XVI гасыр.

Митюк авылы (Нократ карьясенең бер өлеше), Киров өлкәсе.

Алгы ягында (калку язулы):

Тәрҗемәсе	**Текст**
Йә, Мөхәммәд, Йә, Гали! Рәхимле, Шәфкатле Аллаһның исеме белән. Ул. (Аллаһ) мәңге үлемсез.......... Аллаһ әйтте: .... һәркем	يا محمد يا على بسم الله الر حمن الرحيم هو الحى الذى لا يموت قل الله .... كل..... ....

Үлчәмнәре: 11 х 60 х55 см.

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

Искәрмә: Шул чорларда булган гадәт буенча,
кайбер хәрефләрнең өстендә я астында нокталар куелган

№ 39

2 : 1 : № 2.

Җумаш Сәйдтәк улына куелган кабер ташы[35], 1520 ел. Нократ авылы, «Мазар зираты» («Мазар хәберлеге»), Киров өлкәсе.

Алгы ягында (калку язулы):

Тәрҗемәсе	Текст
Йә, Мөхәммәд! Йә, Гали! Искә алыгыз Сәид- тәк улы Җумашны. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһның исеме белән. Һәр төреклек үлә, әмма Ул (Аллаһ) үлемсез. Әлбәттә, үлем ачысын һәркем татыячактыр, соңра кубарылып, Миңа кайтырсыз. Тугыз йөз егерме алтынчы елда Рәҗәб аенда Җумаш Сәидтәк улы Но- крат (авылында) шәһид булды.	يا محمد يا على ياد قيل سيد ني جوماش تك اوعلى بسم الله الرحمن الرحيم كل حي سيمود واهو حي لا يموة كل نفس ذا يق الموت ثم ان ايلنا... ترجعون تاريخ توقوز يوز ينكرمي التى دا رجب اي دا سيدتك نك اوعلى جوماش نو قراتدا شهد كجدي

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

---

[35] Бу ядкяр турында кара: *Сорокин П.* Арские князья в Карине // Календарь и памятная книжка Вятской губернии на 1897 го / Сост. под. ред. Н.Спасского. – Вятка, 1896. – С. 57-58; *Асаре кадимә (Нократ карьясендә улан кабер ташлары)* // Шура. – 1910. – № 20. – Б. 619-621; *Рахим А.* Болгаро-татарские эпиграфические памятники в Вятском крае // Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТССР. – Казань, 1930. – Вып. IV. – С. 49-57+1 приложение; *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику . – М.-Л., 1960. – Табл. 61; *Вәлидов Җ.* Нократ һәм Глазов татарлары арасында // Татарстан. – 1929. – № 5-6. – Б.40; *Мәрданов Р.Ф. Һадиев И.Г.* Нократның борынгы ташъязмалары // Гасырлар авазы, – 2011. – № 1/2/ – Б.4-12.

Материал: Урындагы кызгылт-көрән төстәге комташ.

Үлчәмнәре: 12×67×125 см.
Координаталары: N 58.604984, E 50.355302.

Искәрмә: 1) Шул чорларда булган гадәт буенча, кайбер хәрефләрнең өстендә я астында нокталар куелган. Мәсәлән: “ س ” син хәрефе астына өч нокта кую гадәте татарларда йегерменче гасырдагы ташъязмаларда да очрый; 1) Мәрхүмнең һәлякъ булган урынын «Нократда» « نوقراتدا » дип укырга кирәк.

Арткы ягында:

Тәрҗемәсе	Текст
Җумаш истәлегенә. Үлем куанычы җитте, безнең куанычыбыз китте. Мәгәр шоңкар булып очты, табылмас теләгәне- без. А...ларыбыз белән өметләр- не ..... китте. Әле дә күңелебез хәсрәттә яна егет. .... егет җаным куан- мый. Тилмереп көткән егет җанымны ала.	یاد جوماش اولوم قوانجسي یتی بزیم قوانجمیز كتتي مكر شونقر بولوب اوجتي تابولماس ایستاكان آ...لاارمز برلا اوموتلار ... ني اوزوبكتي ... دردي حسر... ... یكیت ... یكیت جانوم قوان ... ماي تلمروبكتكان یكیت جانوم الغاتي

№ 40

2 : 1 : № 3.

Сэйдтәк Гали суфый улына куелган кабер ташы[36], 1553 ел. Нократ авылы, «Мазар зираты» («Мазар хәберлеге»), Киров өлкәсе..

Материал: Урындагы кызгылт-көрән төстәге комташ.
Үлчәмнәре: 11×65×139 см.
Координаталары: N 58.604895, E 50.355216.

Алгы ягында:

Тәрҗемәсе	**Текст**
Йә, Мөхәммәд! Йә, Гали! Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһның исеме белән. Һәр төреклек үлә, әмма Ул (Аллаһ) үлемсез. Әлбәттә, үлем ачысын һәркем татыячактыр, соңра кубарылып, Миңа кайтырсыз. Тугыз йөз алтмышынчы елда, Рәҗәб ае-ның ахырында Гали суфыйның улы Сэйдтәк алтмыш	يا محمد يا على بسم الله الرحمن الريم كل حى يمود و هو حى لا يمود كل نفس ذائقة الموت ثم ايلنا ترجعون تاريخ توقوز

[36] Бу ядкяр турында кара: *Сорокин П.* Арские князья в Карине // Календарь и памятная книжка Вятской губернии на 1897 го / Сост. под. ред. Н.Спасского. – Вятка, 1896. – С. 57-58; *Асаре кадимә (Нократ карьясендә улан кабер ташлары)* // Шура. – 1910. – № 20. – Б. 619-621; *Рахим А.* Болгаро-татарские эпиграфические памятники в Вятском крае // Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТССР. – Казань, 1930. – Вып. IV. – С. 49-57+1 приложение; *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику . – М.-Л., 1960. – Табл. 61; *Вәлидов Җ.* Нократ һәм Глазов татарлары арасында // Татарстан. – 1929. – №5-6. – Б.40; *Юсупов Г.В.* Указ. соч. – Табл. 61; *Татар әдәбияты тарихы.* Урта гасырлар дәвере. – Казан, 1984. – Т.1. – Б. 285; *Татар поэзиясе антологиясе.* – Казан, 1992. – 1 к. – Б. 151; *Худяков М.* Очерки по истории Казанского ханства. Репринтное воспроизведение издания 1923 г. – Казань, 1990. – С. 157; *Әхмәтҗанов М.* Нугай Урдасы: татар ... – Б. 196; *Әхмәтҗанов М.* Татар шәҗәрәләре. – Казан, 1995. – Б. 12,16, 22; *Әхмәтҗанов М.* Нугай Урдасы : татар халкының тарихи мирасы. – Казан, 2002 . – Б. 194; *Әхмәров Г.* Нократ болгарлары // Казан мөхбире. – 1906. – 20 июнь; *Марданов Р., Һадиев И.* Нократның борынгы ташъязмалары / Гасырлар авазы – 2011, – № 1/2.- Б.4-12.

яшендә Казанда шәһид булды.	**یوز التمیش دا رجب اي نونك آخرندا علي صوفي نك اوغلي سیدتك التمش یا شندا ایردي قزان داشهید**

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

№ 41

2 : 1 : № 4.

Гали хатынына куелган кабер ташы,[37] 1504 ел. Нократ авылы, «Мазар зираты» («Мазар хәберлеге»), Киров өлкәсе.

Алгы ягында:

Тәрҗемәсе	**Текст**
• *Әгузе билләһи мин әш-шәйтан ир-**раҗим*** • *бисмиллаһир-Рахманир-Рахим* • *көллү нәфсин заикател-мәүт* • *сөммә иләйна тәрҗәгунә* • *каләә ән-нәби галәйһис-сәлам* Тугыз йөз дә тугызынчы елда, Рәҗәб аеның ахырында ирдекем ...... [Гали гаялы] .... [дарел-фәнадин дарелбәкага] рих- [ләт] кылды.	**اعوذ بالله من الشيطان ارجيم** **بسم لله الرحمن الرحيم كل نفس** **ذائقة الموت ثم الينا ترجعون** **قال النبى عليه السلام** **تاريخ توقوز يوز توقوزدا** **رجب آى ننک اخرندا ايرديكيم** **[على عيالى] ....** **[دار الفنادين دار البقاعا] رح[لت]** **[قيلدى]**

Материал: Урындагы кызгылт-көрән төстәге комташ.
Үлчәмнәре: 11×65×139 см. Координаталары: N 58.603865, E 50.360473.

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

---

[37] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику . – М.-Л., 1960. – Табл. 61.

№ 42

2 : 1 : № 5 : А

Билгесез. Кемгә куелганы мәгълүм булмаган таш[38](фрагмент,өске өлеше юк).

Тау Иле авылы (Татарское Ходяшево), Питрәч төбәге. 1480 нче еллар.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
• .... • Кылсын .... • *Әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә лә йәбка мәдамән бил-карари* • Күрәм дөньяны: җимерек бары, бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары	قيلسون ارى الدنيا حربا بعتبارى فلا يبقى مداما بالقرارى كورارمن دنيانى ويران بارى هميشه باقى ايرمس يوق قرارى

Текст гарәп һәм татар телләрендә язылган.

[38] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Татарские эпиграфические памятники XV в. (К вопросу о происхождении Казанских татар) // Эпиграфика Востока. – М.-Л., 1951. Т. 5. С. 89-90.; *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – С.78-92. (Фото); *Гариф Н.Г.* Казан ханлыгы чоры ташъязмалары. Казан: ТФА Тарих институты басмаханәсе, 2010. – Б.24.; *Гариф Н.Г.* Болгар-татар ташъязмалары / Булгаро-татарские надгробные камни. Казан: Иман, 2012. – Б.170.; *Һадиев И., Мәрданов Р.* Тау Иленең ташъязма истәлекләре. // Чын мирас. – 2019. – № 4. Б.28.

Уеп язылганнары

№ 43

2 нче өлеш : 1 нче бүлек : № 6 таш

Әюб Мөхәммәд угылына куелган кабер ташы[39]. 1472 ел.

Олы Нырсы авылы, Теләче районы.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *бисмиллаһир-Рахманир-Рахим* • *көллү нәфсин заикател-мәүт* • *сөммә иләйна тәрҗәгунә* тарих • сикез йөз йетмеш йетедә рәҗәб ае • әүвәлендә ирде шинбә көн ирде • Мөхәммәд углы дарелфәна • дин дарелбәкага рихләт • кылды Хак Тәгалә • рәхмәт кылгай инша Аллаһ Тәгалә амин *раббил галәмин*	بسم الله الرحمن الرحيم كل نفس ذايقة الموت ثم الينا ترجعون تاريخ سيكز يوز يتميش يتى دا راجب اي اولينده اردى شنبه كون اردى محمد اوغلى ايوب دار الفنا دين دار البقا غا رحلت قيلدى حق تعالى رحمة قيلغاي انشا الله تعالى امين رب العالم

[39] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Приложение: табл.52.;

№ 44

2 : 2 : №1.

Мәүлә Шаһгали дәрвиш хәляле Нази Мәликкә куелган кабер ташы[40]. Иске Казан зираты. (Биектау районы).

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *һу әл-Хәййү әл-ләзи лә йәмүт вә көллү хәййүн сә-йәмүт* • *калә Аллаһу Сөбханә вәТәгалә вә ма тәдәрри* • *нәфси баи арди тәмәүет* • *каләән-нәби галәйһис-сәлам әд-дүнйа .....* • тарих тукуз йөздә мөбарәк рәбиг- • ыл-әүвәл аеның ахырында ирде кем • Мәүлә Шаһгали дәрвиш хәляле Нази Мәлик • хатын дарелфәнадин дарелбәкага рихләт • кыйлды *гафәрәл-лаһү ләһа*	هوالحی الذی لایموت وکل حی سیموت قال الله سبحانه وتعالی وماتدری نفس بای ارض تموت قال النبی علیه السلام الدنیا تاریخ توقوز یوزدا مبارك ربیع الاول ای ننك اخریندا ایردی کیم مولاشاه علی درویش حلالی نازی ملك حاتون دار الفنادین دار البقاعا رحلت قیلدی عفر الله

Үлчәмнәре: 14 ˣ 48 ˣ 110 см.

---

[40] Бу ядкяр турында кара: *Рахим А*. Татарские эпиграфические памятники XVI в. // Труды Общества изучения Татарстана. Казань, 1930. Т. I. С. 155-157*; Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Таблица 54; *Гариф Н.Г.* Болгар-татар ташъязмалары / Булгаро-татарские надгробные камни. Казан: Иман, 2012. – Б.230,261.; *Гариф Н.Г.* Болгар-татар ташъязмалары / Булгаро-татарские надгробные камни. Казан: Иман, 2012. – Б.230,261.

№ 45

2 : 2 : №2

Сэид-Ак хажи Хэсэн угылына куелган таш[41]. 1518 ел.

Тау Иле авылы (с.Татарское Ходяшево), Питрэч төбэге.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	**Текст**
• *һу әл-Хәййү әл-ләзи лә йәмүт вә көллү сә-йәмүт* • *калә Аллаһу Сөбханә вә Тәгалә көллү нәфсин заикател-мәүт сөммә иләйна түрҗәгунә* • *Калә Аллаһу Тәгалә вә ма тәдри тәмүтү иннә Аллаһ Галимүн Хәбирүн* • *вә каләән-нәби галәйһи вәссәлләм әл-мөэминүн ля йәмүтүнә вә ләкиннә* • *йәнкыйлүнә мин дарелфәна илә дарелбәка каләән-нәби галәйһи вәссәлләм әд-дөнйа сагать* • *фәәҗәгалһа тагать* тарих тукуз йөз йегерме түртдә • Җөмадиәл-ахыр аеның әүвәлендә ирде кем хажи	هوالحى الذى لايموت وكل حى سيموت قال الله سبحانه وتعالى كل نفس ذايقه الموت ثم الينا ترجعون قال الله تعالى وماتدرى نفس باى ارض تموت ان الله عليم حبير وقال النبى عليه السلام المؤمنون لايموتون ولكن ينقلون من دار الفنأ الى دار البقأ قال النبى عليه السلام الدنيا ساعة فاجعلها طاعه تاريخ توقوز يوز يكرمى تورتدا جمادى الاخراى نك اولينداايردى كيم حاجى حسن اوعلى سيداق ياشندادار الفنادين دار البقاعا رحلت قيلدى

[41] Бу ядкяр турында кара: *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Таблица 59.; *ҺадиевИ.,МэрдановР.* Тау Иленең ташъязма истэлеклэре. // Чын мирас. – 2019. – № 4. Б.29.

• Хәсән угылы Сәйд-Ак* • Алтмыш түрт яшендә дарелфәнадин дарелбәкага рихләт кыйлды	

Искәрмә: Һарун Йосыпов китабында: “Шайдулла” дип укылган.

Үлчәмнәре: 23 ˣ 65 ˣ 100 см.

№ 46

2:2:№3

Шәех Нәҗем угылы Чирүчегә куелган кабер ташы[42]. 1505 - 1513 нче еллар арасы. Иске Өҗем авылы (Старый Узюм), Әтнә районы.

[42] Бу ядкяр турында кара: *Рахим А.* Татарские эпиграфические памятники XVI в. // Труды Общества изучения Татарстана. – Казань, 1930. – Т. I. – С. 166.; *Гали Рәхим:* тарихи-документаль, Әдәби һәм биографик җыентык / төз.: Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б.267.; *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Издательство АН СССР, 1960. – Таблица 58.; *Гариф Н.Г.* Болгар-татар ташъязмалары / Булгаро-татарские надгробные камни. – Казан: Иман, 2012. – Б.160.; *Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г.* Әтнә төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б.162.; *Гайнетдинов А.М.* Әтнә районы эпиграфик истәлекләре. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. – Б.85.

Алгы ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
• *һу әл-Хәййү әл-ләзи лә йәмәт вә көллү хәййүн сә-йәмүт* • *калә Аллаһу Сөбһанә вә Тәгалә вә ма тәдәрри нәфси* • *баи арди тәмәүет каләән-нәби галәйһиссәлам* • *әд-дүнйа сәгать фәәҗәгальһа тагать* • *калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дүнйа мизрагат-* • *ел-ахирәт* тарих [тукуз йө]з ун • ту[...]да шәгъбан аенда Шәехнәҗем угылы • Чирүҗе даре фәнадан даре бәкага рихләт кылды	هوالحی الذی لایموت وکل حی سیموت قال الله سبحانه وتعالی وماتدری نفس بای ارض تموت قال النبی علیه السلام الدنیاساعه فاجعلهاطاعه قال النبی علیه السلام الدنیامزرعة الاخرة تاریخ توقوزیوزاون تو داشغبان ایند اشیخ نجم اوغلی جروجی دارفنادان داربقاعارحلت قیلدی

Уң ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
Күрәм дөньяны: җимерек бары, бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары	کورارمن دنیانی ویران باری همیشه باقی ایرمس یوق قراری

Сул ягында (калку язулы):

Укылышы	Текст
Әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари *Фә лә йәбка мәдамән бил-карари*	اری الدنیا حربا بعتباری فلا یبقی مداما بالقراری

Үлчәмнәре: 20 × 52 × 120 см.

№ 47

2:2:№4

